ИРЛӘРЧӘ СӨЙЛӘШҮ

Мобилизацияләнгән Татарстан егетләре кыска ялларын заяга уздырмый

> 2



КУРКЫНЫЧ ЯРАТУ

Ике сүзнең берендә ул: «Үзем гаепле, кияүгә чыкканчы сыныйсы икән ирне...» – дип куя

> 3

СӘРИЯ ГЫЙЛЬФАНОВА:

«Йөзьяшәр әби туганым булмаса да якын»

> 4

ҮЛМӘГӘН, ЙОКЛАГАН ГЫНА

Агачларга зыян салган кортка каршы... нефть белән көрәшәбез

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 102 (29069) | Чәршәмбе | 19 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

«АКЫЛЛЫ» ЮЛ

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ АЛЕКСЕЕВСК – ӘЛМӘТ ЮЛЫ ТӨЗЕЛЕШЕНДӘ БУЛЫП КАЙТТЫ

Киләсе елда Татарстанда яңа юл ачылачак. Алексеевск – Әлмәт автомобиль юлы аша нефть каласыннан Казанга ике сәгатьтә барып җитеп булачак, дип фаразлана. Хәзер исә бер шәһәрдән икенчесенә кадәр дүрт сәгатьләп барасы. Шәле – Баулы түләүле трассасы кысасында төзелүче Алексеевск – Әлмәт юлын журналистларга да күрсәттеләр.

Шәле – Баулы автомобиль юлы М7 һәм М5 федераль трассаларын тоташтырачак. Озынлыгы 145 чакрым тәшкил иткән Алексеевск – Әлмәт юлыннан тыш аңа, Әлмәт белән Баулы арасындагы 100 чакрым чамасы юл (әлегә бу юнәлештә төзелеш башланмаган. – **Ред.**) һәм Саескан тавыннан Шәлегә кадәр гамәлдәге 40 чакрымга якын юл керә. Бүген Алексеевск – Әлмәт юлында эш кайный. Татарстанда булачак магистральгә зур әһәмият бирәләр. Хәер, моны аңлау өчен, юлчылар янына бер барып карау да җитә. Алексеевск районында каләм әһелләрен Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов каршы алды.

– Шәле – Баулы автомобиль юлының бер өлеше булган Алексеевск – Әлмәт юлы төзелеше өч этапка бүленгән. Юлның гомуми озынлыгы 145 чакрым тәшкил итә. Аны киләсе елның декабрендә үк кулланышка тапшыру күздә тотыла. Юлның бәясе 102 миллиард сум, – диде министр.

Татарстанның көньяк-көнчыгышында яшәүчеләр өчен Алеексеевск – Әлмәт юлы төзелеше таныш инде. Бу магистральне салу тәкъдиме белән 2006 елда ук «СМП-Нефтегаз» оешмасы чыккан булган. Татарстан Хөкүмәте аны хуплаган һәм республикада зур төзелеш башланган.

– 2022 елның гыйнварында бу эшкә бәйле концессион килешү төзелде, – диде Фәрит Хәнифов.

Концессион килешү ул – дәүләт белән шәхси бизнес арасындагы хезмәттәшлек, дип ачыклык кертте министр. Бу очракта инвестор итеп «Автострада» акционерлык җәмгыяте билгеләнгән. Гади сүз белән әйткәндә, шәхси оешма юл сала да аны ил күләмендә куллануга тапшыра. Түләүне җыю мәсьәләсе исә аның карамагында кала.

Төзелешнең беренче этабы өчен «СМП-Нефтегаз» җаваплы. Алар эшнең шактый өлешен башкарган да инде.

Алексеевск – Әлмәт юлы – саннарда

Яңа магистраль Татарстанның **5** районын (Алексеевск, Чистай, Яңа Чишмә, Чирмешән һәм Әлмәт) М7, М5 һәм М12 федераль трассаларына тоташтырачак.
42 ярдәмче корылма, шул исәптән **9** күпер, **2** транспорт чишелеше төзеләчәк.
Төзелештә **3** мең кешегә эш урыны булдырыла.

Автор фотосы

Юлны күтәрткәннәр, асфальт җәйгәннәр, аның соңгы катын соңрак түшәячәкләр, ике яклап икешәр полосалы юлның уртасында ут баганаларына кадәр бар. Яңа юлның әзер өлешеннән «ВТ» хәбәрчесе дә йөреп карады. Әлегә бушка.

– Бу юл беренче категориягә карый, – ди «СМП-Нефтегаз» генераль директоры Олег Шабалин. – Төп үзенчәлеге: ул башка юллар белән бер яссылыкта кисешми. Мондый урыннарда ул йә җир астыннан, йә өстән уза. Түләүле юлда тизлек зур булу аңлашыла. Куркынычсызлыкны тәэмин итү дә мөһим, әлбәттә. Бу да уйланылган: кыш көне бозлавыкта югары тизлек белән баручы машина юл читенә төшеп капланмасын өчен, юл кырыйларын билгеле бер яссылыкта эшлиләр.

Яңа юлны якын-тирә авылларда яшәүчеләр үз итәргә өлгергән дә инде. «Выжылдатып кына узып китәләр, үзебезгә дә як-якка каранып кына йөрергә туры килә», – ди юлчылар, уенын-чынын бергә кушып. «Ә түләүле юл ачылгач, мондый «куян»нарны ничек тотачаклар?» – дип тә кызыксындык юл салучы белгечләрдән.

– Бу юлда бернинди шлагбаумнар да булмаячак, әмма аңа теләгән җирдән кереп тә булмаячак, – дип аңлатты «Главтатдортранс» оешмасы директорының беренче урынбасары Александр Куканов.

Машиналар махсус рамка аша узачак. «Акыллы» система машинаны шунда ук танып беләчәк һәм аның хуҗасына «сәлам хаты» юллаячак.

– Юл төзелешенең икенче һәм өченче этапларында ике меңләп кеше эшли, – диде әлеге эш өчен җаваплы «Алексеевскдорстрой» оешмасы генераль директоры Марат Саттаров. – Безгә юлның 102 чакрымы туры килә. Ел ахырына кадәр шуның 90 чакрымына бер кат таш түшәп бетерергә ниятлибез. Киләсе елга эш күп калмый. Кулланышка тапшыргач, әлеге юл Казан – Оренбург федераль трассасын бушатырга һәм юл һәлакәтләре санын киметергә ярдәм итәчәк.

Марат Саттаров сүзләренә караганда, яңа юлда, без күреп ияләшкәнчә, «буразна»лар да барлыкка килмәячәк. Чөнки заманча итеп төзиләр. 1,3 метр биеклектәге юлга асфальтны гына да өч кат җәяләр. Түләүле юлдан сәгатенә 130 чакрым тизлек белән җилдерергә мөмкин булачак, ди.

– Бүген «Төньяк – Көньяк» коридорының әһәмияте зур. Яңа юл Көнбатыш – Көнчыгыш юнәлешендә дә, Төньяк – Көньяк юнәлешендә дә үсеш мөмкинлеген тәэмин итәчәк. Бу Татарстан гына түгел, ил икътисады өчен дә әһәмиятле юл булачак, – диде Фәрит Хәнифов.

Яңа юлдан хәрәкәт итү бәясе турында да кызыксындык. «Әлегә мондый исәп-хисап ясалмаган», – дип кенә җавап бирде министр. Көтәсе күп калмады.

Җәһәт интернет килә

Дәүләт хезмәтләре порталында киләсе елда авылларны югары тизлекле мобиль интернетка тоташтыру өчен Россия күләмендә тавыш бирүнең өченче этабы башланган. Анда халык саны 100дән 500 кешегә кадәрге торак пунктларда яшәүчеләр тавыш бирә ала. Тик алар бары тик үзләренең авылын гына сайлап алырга мөмкин.

Тавыш бирү 13 августка кадәр дәвам итәчәк. Аның нәтиҗәләре буенча 2024 елда телефоннар бик әйбәт тоткан интернет пәйда булырга тиешле 87 авыл сайлап алыначак.

Тавыш бирү нәтиҗәләре 18 декабрьгә кадәр gosuslugi.ru порталына урнаштырылачак.

Татарстанда 2022 һәм 2023 елларда программаны тормышка ашыру барышында 99 авылны җәһәт интернетка тоташтыру планлаштырылган. 44 авылда моның өчен тиешле станция урнаштырылган да инде. Ел ахырына кадәр ул тагын 55 салада пәйда булачак.

Табиб авылны сайлый

Яшь табибларны медицина өлкәсенә, шул исәптән авылларга җәлеп итү өчен, Россия Хөкүмәте күп кенә чаралар күрә. Әйтик, «Авыл табибы» («Земский доктор») һәм «Авыл фельдшеры» («Земский фельдшер») программалары буенча сала-бистәләргә 60 мең белгеч күченеп кайткан инде. РФ сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко әйтүенчә, бу программалар нигезендә эшкә кайтучыларга түләүләрне арттыруны күздә тоткан карар чыгарылган.

Министр сүзләренә караганда, пандемия чорында медицина вузларына укырга баручылар – 26, субординатурага керүчеләр (тар белгечлек алу өчен) 95 процентка арткан. Нәтиҗәдә участок терапевтлары, онколог, анестезиолог-реаниматологлар сафы шактый ук ишәйгән.

Биш елга озайттылар

Запаста булуның чик яше 5 елга арттырыла. Дәүләт Думасы тиешле закон проектын өченче укылышта кабул иткән. Рядовой, матрос, сержант, старшина, прапорщик һәм мичманнарга кагыла бу.

Шулай итеп, беренче разрядлы хәрби бурычлыларга запаста булу вакыты 35тән 40 яшькә, икенче разрядлыларга – 45тән 50 яшькә, өченче разрядлыларга 50дән 55 яшькә кадәр арттырыла. Разрядның хәрби белгечлеккә карап бирелүен искәртеп үтик. Закон киләсе елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Документта аныклап үтелгәнчә, запаста булу яше әкренләп кенә күтәреләчәк. Әйтик, 2024 елда 50 яшькә җитүчеләр – 51 яшькә кадәр, 2025 елда 50гә җитүчеләр – 52 яшькә, 2026, 2027 елда 50гә җитүчеләр 53, 54 яшькә кадәр запаста булачак.

Шунысы да бар: 2024 елга кадәр отставкага киткән 50дән 54 яшькә кадәрге кешеләр янә запаска кертелми. Бу үз теләге белән хезмәт итәргә ниятләүчеләргә генә кагылмый.

Ә инде өлкән офицерларның резервта булу вакыты – 65 яшькә, кече офицерларныкы 60 яшькә җиткерелгән.

vk.com

һава торышы

Рәхәт булачак

Адәм баласына ярап булмый. Эсселәтеп җибәрсә, кайчан суытыр, ә суытса, кайчан җылыта инде, дибез. Холкыбыз да үзгәреп торучан һава торышыныкы кебек. Яңгыры да, кояшы да кирәк үзебезгә. Алда безне нинди көннәр көтә? Эсселәр тагын булырмы?

Казан федераль университеты профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев белдергәнчә, алдагы көннәрдә уңай һава торышы көтелә. Температура климатик нормага якын булачак. Россия гидрометеорология үзәге бу көннәрдә 24–26 градус җылы вәгъдә итә. Кыска вакытлы яңгырлар да сибәләп үтәчәк. Бу атнаның пәнҗешәмбе, җомгасында явым-төшемнәр күрсәтә. Әмма ул республиканың барлык районнарында да бертигез ява дигән сүз түгел. Кызганыч, бездә корылык. Әмма 50 градуслы эсселәр көтелми.

Кыскасы, табигать кискен генә үзгәрмәячәк. «Бернинди куркыныч та, әллә ни әйбәт әйбер дә юк», – диде Юрий Переведенцев, сүзен йомгаклап.

Ә халык синоптиклары ни ди?

Киров өлкәсендәге Пенәгәр авылында яшәүче Салих абый Шәрипов икеләнә:

– Көннәр аяз булырга тиеш иде, яңгырлар явып тора. Кышын декабрьдә кар әйбәт яуды, ә гыйнвар, февральдә юк. Җәй белән кыш хәзер бик чагышмый. Буталчыграк шул. Яңгыр яуса да, ныгытып яумаячак. Эсселәр бетмәде әле.

Балтач районының Пүскән авылында яшәүче элек агроном булып эшләгән Габдерәүф абый Сәлахов быел һава торышын дәфтәргә язып бара башлаган.

– 17 гыйнварда буран булган, 17 июльдә яңгыр явып үтте. Менә анысы туры килде. Тик һәр буран – явым-төшем дигән сүз түгел. Шуңа күрә кыш белән җәйне бик туры килә дип әйтеп булмый. Дәфтәрдәге фаразлар буенча 25–29 июльдә яңгырлар яварга мөмкин, – ди Габдерәүф абый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Суытып җибәрә күрмәсен, дисәк тә, яңгырын да көтәбез. Бер күктәге болытларга, бер сары иңгән үләннәргә карыйбыз. Кызганыч бит. Районнарда да, уракка кадәр бәрәңгеләргә сендерерлек итеп яңгыр яусын иде инде, диләр. Тик кабарган болытлар күп очракта алдап кына китә. Бу көннәрдә кайдадыр шәпләп явып үтсә, кемгәдер бөтенләй эләкмәгән. Кукмара районының Купка авылында коеп яуган. Майдан бирле көткәннәр яңгырны.

– Ниһаять, безгә дә яңгырдан өлеш чыкты. Бик сөендек. Бакчага берничә ел сенаж салам. Менә шул вакытта бер генә тапкыр да яумыйча калмый. Быел да шушы вакытка туры килде, – ди Нурсил Шәймәрданов.

Сәрия МИФТАХОВА

Сүзгә-сүз

Виталий МИЛОНОВ, Дәүләт Думасы депутаты:

– Сосновский балтырганының таралуына гамьсезлек һәм хуҗасызлык сәбәпче. Яшерен-батырын түгел, оешмалар һәм шәхси затлар милкендәге кырлар, кишәрлекләрнең күбесе ташландык хәлдә. Бу исә – әлеге зарарлы үсемлекнең үрчүенә менә дигән җирлек. Балтырган үсә икән, ул җирне куллануны һәм сатуны тыярга кирәк.

«Парламентская газета»дан

РОССИЯДӘ – СӘЛАМӘТ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ

«Росгосстрах Жизнь» һәм «Открытие» банкы үткәргән уртак сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Россиядә яшәүчеләрнең дүрттән өче спорт белән шөгыльләнә.

НИНДИ СПОРТ ТӨРЕНӘ ӨСТЕНЛЕК БИРӘЛӘР?

Авыручылар арта

Ел башыннан бирле Татарстанда 84 кеше кызамык йоктырган. Чирләүчеләрнең яртысы диярлек – 39ы – балалар. Роспотребнадзорның республикадагы идарәсеннән хәбәр ителгәнчә, 20,6 мең кешенең кызамык ияртүчеләр белән аралашканлыгы ачыкланган. Шуның 3839 е – балалар.

Сырхаулар белән аралашкан 2890 кеше прививка ясатырга тиеш булган. Шуның 79,2 проценты (2288 кеше) вакцинация узган. Сүз уңаеннан, июнь аенда идарә башлыгы Марина Патяшина республикада кызамык йоктыруның 72 очрагы теркәлүен белдергән иде. Шулай итеп, чир ияртүчеләр саны тулыр-тулмас өч атна эчендә 12гә арткан.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ҮЛЕМ ҮЗӘНЕНДӘ КАЙНАР ҺАВА

Җир шарында һава торышы рекордлар куя. Калифорниядәге Үлем Үзәнендә якшәмбедә һава температурасы күзәтүләр тарихындагы югары күрсәткечләрнең берсенә иреште. Фернас-Крик дигән урында Цельсий буенча 53,33 градус эсселек теркәлде. Дөрес, 1913 елның июлендә анда 56,67 градуслы һава да күзәтелгән. Метеорологлар, бу юлы көннең болытлы булуы гына яңа дөнья рекордыннан саклады, диләр.

Планетаның башка почмакларында да эсселек газапка әверелә. Кипрда урманнар яна, Берлин зоопаркында хайваннарга туңдырылган яшелчә һәм җиләк-җимеш бирәләр.

Сәяси кайнарлык температурасы да гадәттәгедән югары. Россиянең ашлык килешүеннән чыгуын дөнья дәүләтләре дә, халыкара җәмәгатьчелек тә кискен гаепли. БМО, АКШ, Германия, хәтта Кытай бу уңайдан тискәре белдерүләр ясады. Кытайлар гадәттә халыкара мәйданда Мәскәүне яклап чыгыш ясый. Бу юлы Кремль адымын Пекинда хупламаулары аңлашыла, чөнки ашлыкның иң зур өлеше – 23 проценты Кытайга озатылган. Италиянең авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре ассоциациясе Coldiretti ашлык килешүен туктату дөнья базарларын тетрәтергә һәм азык-төлек белән проблемалар булган төбәкләрдә сәяси тотрыксызлыкка китерергә мөмкинлеген әйтә. Бу шау-шуда газета хәбәрчесе бер нәрсәгә игътибар итә: Россия ашлык килешүен озайтырга каршы түгел, ул бары базарга үз ашлыгын да чыгаруны гына сорый. Россия ашлыгы да чыгарылса, базарларда муллык артачак кына, әмма бер сәясәтче лидер да бу дәлилне колагына элми. Димәк, азык-төлек тирәсендә аек акылга сыймый торган ниндидер бер сәер уен бара. Бу уенда Кремль сәяси очколар югалта.

Бары тик Әрдоган гына ашлык килешүенең Мәскәү катнашында озынайтылачагына шикләнми. Ул Якын Көнчыгыш илләренә визит белән чыгып китте. Төрек икътисадына 50 миллиард долларлык инвестицияләр алып кайтырга ниятли. Сәяхәткә чыгып китәр алдыннан Истанбулдагы пресс-конференциядә: «Бүген иртән Мәскәүдән яңгыраган белдерүгә карамастан, Путин гуманитар коридорны дәвам итәргә тели», – дип белдерде.

Халыкара киеренкелеккә китергән төп сәбәп – дөньякүләм әҗәтләрнең түли алмаслык булып баштан ашуы. Барлык конфликтларның да нигез ташы бу. Бурычлар кискенлеге исә – хәл ителмәслек дәрәҗәдә. БМО Генераль секретаре Антониу Гутерриш: «52 ил дефолтка якын һәм киләчәктә аларның әҗәт йөген киметергә мөмкинлекләре юк», – дип белдерде. Ул илләрнең яртысы гына дефолт игълан итсә дә, бөтен дөньяның финанс системасы әйләнеп капланачак. Һиндстанда «Зур егермелек» илләренең финанс җитәкчеләре ике көнлек очрашуга җыелды. Алар глобаль бурыч кризисыннан чыгу юлларын эзләргә телиләр. Юл исә юк.

Россиядә

АВТОМОБИЛЬНЕ ӘРМӘННӘРДӘН АЛ

Санкцияләргә бәйле рәвештә Россиянең финанс системасы һәм эчке базары зур үзгәрешләр кичерә. Россия кибетләрендә ялган техника арта. 100 смартфонның 31е оригинал түгел, диләр. Киләчәктә бу юнәлештә вазгыять тагын да начараер дип фаразлана.

Үзәк банк илдә финанс пирамидалары санының 19 процентка артуын игълан итте. Кешеләр үз теләкләре белән акчаларын мошенниклар кесәсенә күбрәк сала башлаган дигән сүз бу. Илдә акча кытлыгы, дибез, әмма россиялеләр арасында акчаны кая куярга белмәүчеләр саны шактый зур. 2023 елның беренче яртыеллыгында ватандашларның чит илләрдә күчемсез милек сатып алулары 36 процентка арткан. Бер нәрсәне истә тотарга кирәк: 2022 елда бу өлкәдә үсеш темпы ике тапкыр үскән. Хәзер россияле акча капчыклары күчемсез милекне Төркия белән Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә генә түгел, Кариб бассейнындагы экзотик илләрдә дә күпләп ала башлаган. Байларны күчемсез милеккә инвестиция ясап, гражданлык алу мөмкинлеге кызыктыра.

Илнең җиңел автомобиль базарында үзгәрешләр бара. Япон Хөкүмәте Россиягә двигатель күләме 1,9 литрдан зуррак булган автомобильләр кертүне тыярга җыена. Тыю августтан башланыр дип көтелә. Япон машиналарын сөючеләр өчен эш катлаулана, димәк.

Россиялеләр бик аптырап тормый ләкин. Дус илләр аша автомобиль сәүдәсе бар көченә эшли. Әрмәнстан – үз автомобиль сәнәгате булмаган ил – безгә автомобиль экспортын кискен темплар белән үстергән. 2022 елның гыйнварында россиялеләр Әрмәнстан аша 800 мең долларлык автомобиль кайтарган булсалар, 2023 елның гыйнварында аннан машина сатып алу күләме 180 миллион долларга җиткән. Элек бай россияле импорт автомобильләрне автосалонга бара да ала иде. Хәзер Көнбатыш маркаларын ул юл белән алу мөмкинлеге бетте диярлек. Трейдерларга мөрәҗәгать итәргә туры килә. Күпчелек автомобильләр АКШтагы иминиятләштерү аукционнарында сатып алына икән. Авария хәлендәге машиналар анда арзанга сатыла. Шуннан соң аларны Грузиядәге Поти порты аша китереп, Әрмәнстанда ремонтлыйлар, шулай арзанга чыга. Таможня контролен Ереванда үтәләр, чөнки әрмән башкаласы белән Мәскәү арасында пошлинасыз сәүдә турында килешү бар. Россиядә автомобильләр күпкә кыйммәтрәк бәядән сатыла. Үткән ел безнең автомобиль базарында сатылган машиналарның дүрттән өч өлешен тотылган автомобильләр тәшкил иткән.

Әрмәнстан АКШтан автомобиль импортлауны айдан-айга кискен темплар белән арттыра. Россиягә экспорт та шундый ук темплар белән үсә. Ул арада Россия хакимиятләре ОСАГО ремонты вакытында кулланылган запчастьлар файдалануны законлаштырырга җыеналар дигән хәбәр бар. Федерация Советы шул мөмкинлекне тормышка ашырырга тели, ди. Бу хакта «Известия» яза.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

ИСКЕ ЮЛДА ЯҢА ХЕЗМӘТТӘШЛӘР

Күптәнге хезмәттәшлекне тагын да ныгытасы булыр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Төркиянең Конья шәһәрендәге очрашу вакытында шулай дип белдерде. Искәртеп үтик: республика делегациясе – Төркиядә эш сәфәрендә. Рәис, сәүдә-икътисадый мөнәсәбәтләрне ныгыту йөзеннән, андагы төбәкләр белән танышуны дәвам иттерде.

Татарстан белән Төркия арасындагы сәүдә-икътисадый мөнәсәбәтләрне сан теленә күчереп әйтсәк, 2022 елда ике арадагы товар әйләнеше 1,2 млрд долларны тәшкил итте. Бу – 2021 елгы саннар белән чагыштырганда 2 тапкыр күбрәк күрсәткеч.

Төркияне Татарстанда да «табарга» була. Рөстәм Миңнеханов сүзләре белән әйтсәк, Төркия компанияләре республикага 2 млрд доллар күләмдә инвестиция керткән. Татарстан территориясендә «Кастамону Энтегре», «Хаят Кимья», «Шишеджам», «Джошкуноз», «Колуман», «Тирсан Кардан» һәм башка заводлар уңышлы эшли.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, хәзер хезмәттәшлек күләмен арттыру күздә тотыла, шул исәптән Конья бизнесы белән дә. Бу хакта ул Конья сәнәгать палатасы рәисе Мостафа Бююкэген белән очрашу вакытында белдерде.

Республика рәисе Татарстанның икътисадый, сәнәгый һәм инвестицион яктан көчле якларын билгеләп үтте. Төбәк өчен нефть табу, нефть эшкәртү, машина төзелеше һәм башка тармаклар кызыклы булыр иде.

Рөстәм Миңнеханов Төркия сәүдә министры урынбасары Мәхмүт Гүрҗән белән дә очрашты. Мәхмүт Гүрҗән Татарстанның Россия һәм Төркия арасында төбәкара хезмәттәшлекне үстерүгә зур өлеш керткәнен билгеләп үтте. «Без Татарстан белән сәүдә-икътисадый элемтәләрне үстерүгә зур әһәмият бирәбез. Бу юнәлештә эзлекле эш алып барабыз», – диде ул.

Татарстан Рәисе Төркия Сәүдә министрлыгына Татарстан – Төркия хезмәттәшлегенә ярдәм иткән өчен рәхмәт белдерде. «Без киләчәктә дә Төркия партнерлары белән актив эшләячәкбез. Бүген безнең товар әйләнеше 1,2 миллиард доллардан артып китә, динамика бик уңай. Ләкин бу тынычланырга дигән сүз түгел. Киресенчә, без Коньяга яңа партнерлар табарга, аларны Россиягә чакырырга, шуның белән эшлекле элемтәләребезне активлаштырырга килдек», – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов.

Эш сәфәре кысасында Рөстәм Миңнеханов Коньядгы «Имаш» заводында да булды. Әлеге завод авыл хуҗалыгы җиһазларын җитештерүгә махсуслашкан. Татарстан Рәисе «Имаш» җитәкчелегенә республикада да эшчәнлекләрен җәелдерергә тәкъдим итте. «Үз чиратыбызда сезгә барлык шартларны да тудырачакбыз», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Моннан тыш республика Рәисе «Тюмосан» трактор техникасы җитештерү заводында да булды. Рөстәм Миңнеханов аның эшчәнлеге белән танышты, техника үрнәкләрен карады.

Белешмә

Конья Төркиянең авыл хуҗалыгы машиналары төзү өлкәсендә лидер булып тора. Төбәктә 13 сәнәгать зонасы, 95 сәнәгать паркы эшли. Шуларда 8,6 мең компания урнашкан. Конья Төркиядә экспорт күләме буенча 12 нче урында тора, ел саен чит илләргә 3,3 млрд долларлык товарлар җибәрә.

ИЯСЕЗ МИЛЕК

Министрлар Кабинетында

Татарстанда 400 меңгә якын күчемсез милек объектының хуҗасын эзлиләр. Төгәлрәк әйтсәк, 376 меңенең милеккә хокукы рәсмиләштерелмәгән. Журналистлар белән очрашу вакытында бу хакта Татарстанның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Фәнил Әһлиуллин хәбәр итте.



kzn.ru

Милек хуҗаларын эзләү һәм табу турында соңрак. Әлегә очрашуда китерелгән башка саннарга тукталыйк. Росреестрның Татарстан буенча идарәсендә беренче яртыеллыкта шактый җыелган алар.

Әйтик, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, быел күчемсез милекне рәсмиләштерүгә гаризалар саны 22 процентка арткан. Хокукларны рәсмиләштерү – 15 процентка, кадастр исәбенә алу 64 процентка күбрәк.

Бу елның алты аенда кабул ителгән 384 мең гаризаның 214 меңе электрон рәвештә килгән. Узган елгы күрсәткечтән 60 процентка күбрәк, ди бу. Электрон рәвештә кадастр исәбенә алу буенча мөрәҗәгатьләр аеруча арткан (5 тапкыр).

Барлык мөрәҗәгатьләрне дә исәпкә алып, бу елның алты аенда идарә белгечләре милек объектларына 713 мең хокук рәсмиләштергән. Узган елның шушы ук чоры күрсәткеченнән 34 процентка күбрәк бу.

– Торак биналар буенча үсеш – 15, җир участокларына 6 процентны тәшкил итә. Машина урыннарына килгәндә, анда башка вазгыять, – диде Татарстан буенча Росреестр идарәсе җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы Илнур Хисмәтуллин. – Былтыр аның буенча шау-шу күп булды. Быел киресен күзәтәбез. Бары тик 4,6 мең хокук теркәлде. Бу узган елгы күрсәткечтән 23 процентка кимрәк.

Кимү беренчел торак базарына да кагылган. Илнур Хисмәтуллин сүзләре белән әйтсәк, 19 процентка. 2023 елның алты аенда күчемсез милекнең беренчел базарында өлешләп катнашу буенча 8,8 мең килешү төзелгән.

Икенчел торак базарына килгәндә, бу тармакта җанлану бар. 2022 елның беренче яртыеллыгы белән чагыштырганда, бу күрсәткеч 8 процентка арткан. 2023 ел башында Росреестр идарәсе 102,8 меңнән артык алыш-биреш килешүе теркәгән (шуларның 42,5 меңнән артыгы торак биналарга, 48,1 меңнән артыгы җир участокларына, 4,5 меңе торак булмаган биналарга).

Торак базары турында сүз чыккач, ипотека турында да берничә сүз. Килешүләр саны буенча уңай динамика күзәтелә, ди Росреестр вәкиле.

– 2023 елның беренче яртыеллыгында Татарстанда ипотека килешүләре саны 2022 елның шул ук чоры белән чагыштырганда 23 процентка артты, – диде Илнур Хисмәтуллин. – Ярты ел эчендә 56,5 меңнән артык ипотека килешүе теркәлде. Шуларның 19,1 меңе – җир участокларына, 27 меңе торак биналарга туры килә.

400 меңгә якын милек объектының хуҗасы юк, дигән идек инде. Фәнил Әһлиуллин аңлатканча, милек варисларына бу хакта мәгълүматны вакытында җиткермәү нәтиҗәсе бу. Мирас булып калгач, милек турыдан-туры алар хокукына күчә дип уйлау – ялгыш, дип кисәтә министр.

Фәнил Әһлиуллин әйтүенчә, җирле үзидарә органнары да андый объектларны ачыклауда, милекнең хуҗаларын табуда ярдәм итә ала. «Алар архивтагы мәгълүматны тикшерә, салым хезмәткәрләреннән һәм хокук саклау органнарыннан мәгълүмат сората. Иясез объектны ачыклаганнан соң, бу хакта мәгълүматны потенциаль милекчегә җибәрә, алар ай ярым вакыт эчендә җавап бирергә тиеш», – дип аңлатты министр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Ватан хакына

«ӨЧПОЧМАК САГЫНДЫРГАН...»

РАЙОН БАШЛЫКЛАРЫ ЯЛГА КАЙТКАН ХӘРБИЛӘР БЕЛӘН ОЧРАША

Махсус хәрби операция зонасыннан вакытлыча туган якларына кайткан Татарстан егетләре кыска гына ялларын заяга уздырмый. Район башлыклары белән очрашуларда катнашып, үзләрен һәм якыннарын борчыган мәсьәләләрне җиткереп калырга тырыша алар. Батыр егетләрне нәрсә борчый? Без янә шуны белештек.

Баулы районы башлыгы Ильяс Гозәеров та мондый очрашуларның чираттагысын уздырган. Туган якларына кайткан егетләр белән ул чәй өстәле янында сөйләшкән. Зарланырга яратмасалар да, хәрбиләрнең берсе – «Мудрый» позывнойлы ир-егет кан басымына бәйле проблемаларын җиткергән, ялга кайткач, хастаханәдә ятып чыгарга да өлгергән. Ә фронттагы хәлләрдән зарланмый егетләр. Ашау-эчү мәсьәләсендә тәртип, көндез артык эссе, ә төнлә артык салкын булуы гына борчый икән үзләрен.

– Өйдә пешкән ризыкны сагынып кайттык. Бездәге өчпочмакның тәмлелеге!.. Андый тәмле өчпочмак башка бер җирдә дә юк, – дип сөйләгән ялга кайтучыларның берсе. – Өйгә кайтыр алдыннан дулкынландым. Ә китү әллә ни авыр түгел. Иң кыены безгә – китүчеләргә түгел, ә озатып калучыларга шул аның...

Акча һәм түләүләр вакытында килеп тора, ә якыннарның һәм туган якның ярдәме көч өсти – иң мөһиме шул, ди егетләр.

Вакытлыча ялга кайткан Чаллы егете Андрей Балеевскихның яңа туган кызы Виктория белән тәүге очрашулары. Шәһәр мэры яшь гаиләгә 100 мең сум акча һәм республика бүләкләре тапшырган.

Чаллы мэры Наил Мәһдиев исә хәрбиләр белән тугызынчы мәртәбә очрашкан. Барлыгы 18 ир-егет килгән. Бу очрашуны алар һәлак булганнарны бер минутлык тынлык белән искә алып башлаган.

– Егетләр белән ничәнче мәртәбә очрашуым – бер зарлану сүзе ишеткәнем юк. Солдатларча: «Бар да тәртиптә», – дип кенә җавап бирә алар. Күрәсең, махсус хәрби операциядә катнашу тормышка башкача карарга өйрәткәндер... – ди шәһәр мэры.

Егетләрнең һәркайсына кирәк-ярак тутырылган рюкзак, җылы аяк киемнәре әзерләнгән булган. Гомумән, шәһәр үз батырларын ташламый – гуманитар ярдәмне илтеп кенә тора. «Туган якка рәхмәт!» – ди егетләр.

– Шәһәребез бик үзгәргән. Үзем яши торган микрорайонны таный торган түгел, – дип уртаклашкан хәрбиләрнең берсе. – Мин кайтканда, балаларыбызның берсе генә өйдә иде, икенчесен авылдан алып килдек. Сөенештеләр... Вакытымны алар белән уздырам. Тиздән – августта хатыным белән бергә яши башлавыбызга 17 ел тула. Бу юлы видеоэлемтә аша гына бәйрәм итәргә туры киләчәк...

Ир-егетләрнең күпчелеге үзләре түгел, якыннары, аеруча балалары өчен борчыла. Өйдәге проблемаларын Наил Мәһдиевкә аерым килеп сөйләүчеләр дә булган. Җитәкчелек якыннарын ярдәмнән ташламас, үзләре өйдән еракта чакта терәк табылыр, дип өметләнә алар.

Аксубай районы башлыгы Камил Гыйльманов махсус хәрби операциядә катнашучы егетләр белән 10 көн саен очрашырга тырыша. Мондый очрашулар май аеннан бирле даими рәвештә уздырыла икән. Район башлыгының мобилизациягә бәйле эшләр буенча ярдәмчесе Вера Саттарова сөйләвенчә, ялга кайткан егетләрне үзләренә һәрдаим ярдәм итүче волонтерлар белән очраштырырга тырышалар.

– Без аларны яшьләр үзәгенә алып барырга тырышабыз. Анда 20ләп волонтер хәрбиләр өчен махсус ятьмәләр үрә. Авыл җирлекләреннән китерүчеләр дә шактый. Яллары бетеп, махсус операция зонасына киткәндә, аларны үзләренә тапшырабыз, – диде ул безгә.

Район хәрбиләрнең туганнарын, якыннарын да ташламый.

– Кемгәдер утын кайтарырга кирәк. Быел иң авыры – печән табу. Ләкин без ничек тә ярдәм итәргә тырышабыз. Әле соңгы очрашуда егетләр генератор сораганнар иде – таптык, тапшырдык. Район башлыгы үзе дә егетләрнең әти-әниләре белән еш очраша. Бу хакта бик сөйләми генә, – диде Вера Саттарова.

Зәй районы башлыгы Разиф Кәримов ялга кайтучылар белән чираттагы очрашуын әле шушы көннәрдә генә уздырган. Очрашуда ул хәрбиләр өчен гуманитар ярдәмнең чираттагы партиясе әзерләнүен хәбәр иткән.

Районның матбугат хезмәтеннән хәбәр итүләренчә, чәй табыны янында узган очрашуда солдатлар үз хезмәтләре турында сөйләгән, гуманитар ярдәм күрсәтүләре, якыннары турында кайгыртулары өчен барлык зәйлеләргә рәхмәтләрен белдергән.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Зәки абый киңәше

Үткән гасырның 90 нчы елларында Зәки Зәйнуллинны белмәгән, аңа сокланмаган кеше калды микән? Ул безнең «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясенә дә еш килгәли иде.

Егетләр кебек төз гәүдәле, әллә кайдан ишетелә торган көр тавышлы иде, матур йөзендә шәп кенә мыек та утырып тора. Ул үзе һәрвакыт каядыр ашыкса да, очраган кеше белән рәхәтләнеп сөйләшер иде. Минем үземә дә Зәки абый белән аралашырга туры килде.

Бүлмәгә килеп керүгә, зур кулларын өстәлгә китереп салып: «Зөлфәт, син рәсем генә ясарга тиеш, гармунда уйнарга, җырларга, язарга да тиеш түгел», – дип әйтә иде. «Ясаган рәсемнәреңне җыеп, китап чыгарырга кирәк, ул сине илебезгә танытачак!» – дип тә өстәп куя иде. Тора-бара мин аның үзенең дә рәссам икәнлеген белдем. Агачтан юнып, кечкенә кеше фигуралары, скульптуралар ясый икән! Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмгә охшатып ясаганын күреп исем китте!

Зәки абый үзен гел Балтач районы Салавыч авылы кешесе дип яшәде. «Минем бабаларым, Пётр I патшалык иткән елларда Малмыж ягыннан Салавычка таба чукындыручылар отряды килә башлагач, аларга һөҗүм иткәннәр һәм соңыннан барыбер, урысларга буйсынмыйча, Башкортстанга – Стәрлебаш авылына чыгып качканнар. Монда алар бик зур эшләр башкарганнар! Бу турыда миңа 1905 елда туган Яңгул авылы карты сөйләгән иде. Ул вафат булгач, кайтып, әле мин аны соңгы юлга да озатыштым!» – дип тә әйтә иде ул. «Әйдә Балтачка, Салавычка кайтып килик инде, берәр җирдә, китапханәдә халык белән очрашулар оештырып булмасмы?» – дип, миңа телефоннан шалтыраткалый иде. Шуннан ул үзе генә Салавычка очрашуга кайтып та килде әле. Мине кайта алмавым өчен шелтәләде дә. Полковник, язучы, драматург, рәссам, милләтебезнең каһарман улы Зәки абый Зәйнуллинны хәзер дә зур хөрмәт, ихтирам белән искә төшерәм. Әйткән сүзен беркайчан да чынга ашырмыйча калмый торган кыю, туры сүзле кеше иде.

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.
Казан

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәниф ШӘРИПОВ

КАКЫ ЫЗАНЫ

Истән чыкмый һаман. Шигырь язам.
Тотып атам янә сызам да.
Бәхет тулы гамьсез көннәр булган
Какы үскән чакта ызанда.
Монда шомырт. Монда бәрәңгеләр.
Менә монда суган түтәле…
Барысы бар. Барысы да җитә.
Юк булгач юк инде бүтәне.
Гафифәттәй белән уртак ызан,
Какы үскән чагы дөньяның.
Сихри мизгел, ләкин ул вакытта
Кем кадерен белгән соң аның?
Язган булам. Кемгә кирәк соң бу?
Тотып атам, сызып бозам да.
Шуны гына беләм: без барында
Какы үсә иде ызанда.
Шомырт корган, ызан сукаланган.
Тулып ята хәзер бүтәне.
Күз алдымда чәчәк тулы ызан,
Какы, шомырт, суган түтәле…

2021

Галстуклы булдым

Өченче класста укыганда, апрель аенда Сания апабыз 21 апрельгә һәрберебезгә кызыл төстәге пионер галстуклары алып килергә кушты.

Көннәр үтә торды, кайбер классташлар берничә көннән инде галстуклары белән мактаныша башлады. Мин һәр көн әнигә галстук турында сүз кузгатам. Ә әнинең җавабы бер генә: «Улым, акча юк бит!» Инде галстукның Буа шәһәре кибетендә кайда сатылганын, бәясе 1 сум 20 тиен торганын да белдем. Билгеләнгән вакыйгага ике көн калды дигәндә, бәлки кызыл чүпрәк кисәге бардыр, шуңардан әзерләргә булыр дип, әнинең өйдәге бар ямаулык төргәкләрен актарып бетердем. Бер кисәк кызыл чүпрәк тә табылмады. Аннары күрше Әсмә әптигә – үземнең кендек әбиемә кереп соранып карадым – булмады.

Менә тагын бер көн үтеп китте. Әни эштән кайтты, тагын: «Акча юк», – дигән җавап ишеттем. Апрель аеның карлы-сулы урамыннан ике мәртәбә әбиемә барып килдем, аңарда да булмады. Инде тыела алмый елап беттем. Дәресләр әзерләргә дә күңел бармый. Өзгәләнеп, җә-

vk.com

берләнеп борчылам – иртәгә пионерга алмаячаклар бит. Ә пионерга кем яхшы укый, тәртип бозмый, шуларны гына алалар. Кичке тугызлар тирәсендә туганнан туган сеңлем Кадәриягә юнәлдем. Ул миннән бер класска алдан укый. Бик җитез кыз. Алар безгә иртәгәсен галстуклар бәйләргә тиеш – мин шуны беләм. Аның белән килештек: мәктәп сәхнәсенә чыккач, ул минем артка баса. Галстуклар бәйләү башлангач, үзенекен сала да миңа бәйли! Аннары күз күрер ничек буласын.

Булачак пионерлар сәхнәгә менеп тезелдек. Артыбызда – 4 нче класс укучылары. Сизәм: минем артта Кадәрия түгел, башка бала килеп басты. Шулчак тегендә-монда боргаланганда, Кадәрия тиз генә тегене читкә этеп, минем артка килеп басты. Һәм директорыбыз Азат абый яшь пионерларны котлап берничә сүз әйткәч, сөйләшкәнчә, үзенең галстугын миңа бәйләп куйды. Дәресләрдән соң мин аңа галстукны кире бирдем. Икенче көнне мин, билгеле, галстуксыз килдем. Ярый әле, мәктәптә сакта күршем Рафаэль тора иде. Без бит бергә уйнап үстек, тоткарлаучы булмады. Берничә көн шулай аптырап йөргәч, әни, ниһаять, галстук алып кайтты. Ул көннең шатлыгын аңлатып булмастыр. Хәзерге яшьләр, әти-әниләре машина бүләк итсә дә, ул кадәр шатланмыйлардыр. Мин чын пионер булдым бит! Башкалардан ким түгелмен!..

Нинди заманнар булган бит: әти-әни ел әйләнәсе бер көн ялсыз колхозда эшли, ә галстук алырга да йортта бер сум акча юк. Гаиләдә биш бала, ничек итеп тормыш ителгән ул заманнарда?

Расих ҖӘЛӘЛ.
Буа районы

АЛТЫН КАШЫКЛАР

Әтинең абыйсы Минһаҗетдинне, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң ук, туган авылы Югары Стәрледә районда иң алдынгы «Мелиорация» колхозының баш хисапчы-бухгалтеры итеп куялар. Бу эштә аның азмы-күпме тәҗрибәсе дә бар, ул җиденче сыйныфта ук җәен учетчы эшен алып бара. Яңа гына шәфкать туташы булып килгән чибәр кыз Зәйтүнә белән очрашалар да гыйшык утында яналар. Бер кызлары Лимуза туып, озак та үтми, дәһшәтле сугыш чыгып, бронь белән калырга булса да, Минһаҗетдин фронтка китә. Ул: «Без Мәскәү астында Вязьмага 40–50 чакрымнарда гвардия укчы полкында», – дип язганнан соң, күп тә тормый, 1943 елның 24 июлендә «Мәскәү өлкәсенең Ильино авылы батырлар каберлегенә җирләнде» дигән кайгылы хәбәр килә. Туасы Лиюзасын бик күрәсе килгән иде бит әткәсенең. Менә шул кыз әтисен күрә алмаса да, гомере буе аңа охшарга тырышып, һөнәрен дәвам итүче булып үсә. Урта мәктәптән соң ук, бик яхшы укыганга, янәшәдәге Вахитов сельпосына учетчы бухгалтер итеп алалар. Уфа шәһәрендә институт тәмамлагач, министрлыкта эшли, аннары «Кызыл таң» газетасында баш хисапчы була. Үтә кызыксындырып, үземне дә шунда тартты, һәм, билгеле инде, ул чакта безнең Азнакай – Бакалы – Дүртөйле – Кушнаренко районнары белән үзара ярышу, дустанә дуслыкларыбыз хакында «Бер елганың ике яры» дип «Кызыл таң»га публицистик язмаларымны да биреп барган идем. Бу вакытта Лиюза үзе дә шигърият белән мавыгып китә. «Бәләкәй чагымда кошлар белән сөйләшә идем. Әбиләр: «Әтиең кайтыр, балам», – дип юаталар иде. Кайтмады», – дип искә ала ул.

Төшләремә керәсең дә
Иңнәремнән кочасың.
Мин киткәчтен туган бала –
Синдер инде, диясең, –

дип әтисен сагынып яза. Әлбәттә, шигъри тәлгәшләрен үзебезнең «Маяк»та бастырып чыгаргач, күңеле бик булыптыр инде, Лиюза апам миңа алтын кашыклар җыелмасы бүләк итте. Ул алтын кашыклар исә – бик истәлекле ядкәр, гүя кадерлеләремне һәр көнне якынайтып, догалы теләкләрен җиткерәләр сыман.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ

Рәсми хәбәр

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Усад авыл җирлегендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата – кварталларның кадастр номерлары 16:16:172101, 16:16:172301, 06.03.2023 ел, № 923000033-ОК дәүләт контрактлары нигезендә, комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Тимофеевка авылы, Профсоюз урамы, 45 нче йорт (телефоны: +7 (84365) 73-2-75), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (Комплекслы кадастр эшләре заказчысы) (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (үз территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең башкарма органы – https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татастан Республикасы буенча идарәсе (кадастр учеты органы – https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез.

Үзләренә карата 16:16:172101, 16:16:172301 кадастр кварталлары территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 31 июлендә 13 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Тимофеевка авылы, Профсоюз урамы, 45 нче йорт) үткәрелә.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 10 июленнән 2023 елның 31 июленә кадәр һәм 2023 елның 31 июленнән 2023 елның 4 сентябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә һәм әлеге каршы килүне җибәргән зат турында мәгълүматларны, шулай ук фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булганда), шулай ук милекче адресын һәм (яки) милекченең электрон адресын, шәхесен раслаучы документы реквизитларын, җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны белән килешмәве сәбәпләре нигезләнешен, җир кишәрлегенең кадастр номерын (булганда) яки территориянең карта планы проекты нигезендә җир кишәрлеге билгеләнешен үз эченә ала. Әлеге каршы килүләргә каршы килүне җибәргән затның мондый җир кишәрлегенә хокукын раслаучы документлар күчермәләре яки мондый җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче яки раслаучы башка документлары, шулай ук мондый җир кишәрлеген булдыруда чикләрнең урнашу урынын билгеләүче (билгеләгән документлар булганда) кушып бирелергә тиеш.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.



«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

«ИРЕМНӘН КУРКАМ...»

Язмыш

Аның кыенлыкларга түзеп яшәгән хатын булуы әллә каян – үз-үзен тотышыннан, кыяфәтеннән үк күренеп тора. Ул аз гына кыштырдаган тавышка да сискәнеп китә, җилкәләрен куыра төшеп, як-ягына карангалап ала. Йөзенә чыккан курку галәмәте аны инде беркайчан ташламас кебек.

– Сөйләсәң дә юк, сөйләмәсәң дә, – ди ул ишетелер-ишетелмәс. – Хәзер берни дә төзәтеп булмый инде. Тик ул шундук килүебез сәбәбе үзе булуын исенә төшерә дә пышылдауга ук күчеп сөйли башлый. Гаҗәпләнеп тә, әрнеп тә аны тыңлыйбыз. Һич онытылмас мизгелләр бу. Түзсә дә түзә икән хатын-кыз… Ике сүзнең берендә ул: «Үзем гаепле, кияүгә чыкканчы, башта сыныйсы икән ирне…» – дип куя. Өйләнешүләре дә бик тиз булган шул аларның. Әллә: «Бай егет, рәхәттә генә яшәрсең», – дип, бертуктаусыз үгетләп торган әнисенең сүзләре шулай тәэсир иткәнме, әллә сизелми дә узып барган гомеренең гаилә кору, балалар үстерү өчен нәкъ вакыты булуы исенә төшкәнме, кыз егет белән танышуына өч ай дигәндә, кияүгә чыгарга риза була.

Ике катлы зур йортка килеп утырган кыз беренче көннәрдә үзен бик бәхетле хис итә. Кая эшкә урнашыйм, дип баш ватасы да юк. Иренең – үз бизнесы. Ул аны үз янына эшкә урнаштыра. Шома, әйбәт барган тормыш бер мизгелдә чәлпәрәмә килә. «Рәхәт дигәнем бик тиз михнәткә әверелде. Хатын-кызны мәсхәрәли торган кеше булып чыкты ул, – дип дәвам итә сүзен золым корбанына әверелгән ханым. – Юк кына нәрсә өчен дә сугып җибәрү, кыйнау аның өчен берни тормый. Беренче мәртәбә кыйнаганы бер дә хәтердән чыкмый. Авырып йөргән чагым иде».

Уллары тугач, «Кемнән таптың?» – дип бәйләнүләре, икенче балага йөкле вакытта ничек итеп җәберләүләре, шуннан соң баласы төшүе, эштән аз гына соңарып кайтса да, өйдә зур тавыш чыгуы, сугарга җай гына эзләп йөрүләре… «Барысы да күз алдында, берсе дә онытылмый», – дип өзгәләнә хәзер үзен тоткында кебек хис иткән хатын. Ул ничә мәртәбә аерылырга азапланып караган. Шулай дия башласа, ире аны: «Китсәң, үтерәм, баланы сиңа бирмим», – ише сүзләр белән куркыткан. Әнисе дә: «Аерылмыйсың, бездә синнән башка да тыгын», – дип кисәтеп торган. Иң якыннары да аннан йөз чөергәч, кая барсын, кемгә барып баш төртсен ул? Утырасың инде әнә шулай, күрәчәгем дип. Ә залим иренең яман гадәте һаман артыннан калмый йөри. Бичара хатынның: «Мәсхәрәли дә урынымнан типкәләп төшерә. Хурланам, елыйм, рәнҗим…» – дигәннәре һаман да колак төбендә җан авазы булып яңгырап тора. Әйе, үзе әйтмешли, күрмәгәне калмаган, барысы да башыннан кичкән аның. Тик менә шул каргышлы, зәхмәтле тормыштан ничек чыгарга икәнен генә белми. Бу хәлләрдән котылу юлын табу өчен безгә – газета-журнал хезмәткәрләренә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән ханым шул чагында: «Юкка гына сезне борчыдым. Шикаять белән беркая бармыйм. Мин инде күнектем», – дип хәйран калдырган иде.

Залим ир кармагына эләккән хатын-кызның кайсы әнә шулай бер кирәкмәскә, адәм мәсхәрәсенә калып түзә, ә кайсы… Ә кайсы проблеманы һич кӧтелмәгәндә, ахырының ни белән бетәсен уйламыйча, язмышына кара мөһер сугып тәмамлый. Болай дигәндә, бөтен республика халкын дәррәү кузгаткан бер вакыйга искә төшә. Шыбырдап яңгыр койган көзге салкын көннәрнең берсендә республика читендә урнашкан төбәкләрнең берсенә барып чыгып, авыл халкын кыл өстендә тотарга мәҗбүр иткән хәлләргә сәбәпче булучыны урам буйлап эзләп йөргәндә, каршыбызга килеп чыккан бер агай: «Теге ирен үтергән хатынны сорыйсызмы?» – дип, безне телсез калдырган иде. Чөнки ни өчен шундый фаҗига килеп чыгуын ул хәсрәтле йортның капкасына үрелгәнче үк якынча белә идек инде без. Гомер буе изелеп, кыйналып, кимсетелеп яшәгән бәхетсез хатынның, күп бала анасының соңгы чиккә барып җитәргә этәргән куркыныч адымын кем ничек бәяләгәндер, тик без аны гаепләргә ашыкмадык. Чандыр гәүдәле, мөлаем ханымны күрүгә: «Нигә, ни өчен?» – дип кенә әйтә алдык.

Нигә, ни өченме?! Түзә алмаган ул эчкече иренең кул уйнатуларына, сабырлыгы төкәнгән. Эчеп егылгач, китереп суккан да үзе сарайга чыгып асылынган. Ярый әле коткарып калганнар. Үзе дә үләсе булган югыйсә.

Үз-үземә кайта-кайта бер үк сорауны куям: гаять четерекле мондый хәлләрдән ничекләр чыгарга соң? Моның ише тетрәндергеч күренешләр бик еш кабатланып тора бит. Илебездә һәр сәгать саен димәсәң, ире тарафыннан бер хатын-кыз үлә. Рәсми мәгълүматларга караганда, кыйнау-җәберләүгә бәйле булган барлык җинаятьләрнең яртысыннан күбрәге өйдә кылына. Әйе, ничек чыгарга бу хәлдән? Әлеге проблеманы дәүләт дәрәҗәсенә күтәреп хәл итәргә кирәклеге көн кебек ачык. Ир белән хатын арасына, гаилә мөнәсәбәтләренә тыкшынмау, башкача әйткәндә, кирәкмәгән әдәплелек, ә бәлкем, гафу ителмәслек битарафлык күрсәтүебез нәтиҗәсендә әнә нинди хәлләргә юлыга асыл затларыбыз?!

…Бервакыт шулай эштән кайтып барам. Күзем подъезд төбендә басып торган бер кызга төште. Бала гына әле үзе. Каршысында гайрәт чәчеп басып торган озын буйлы егет аны иңбашыннан эләктереп алган да селкетепме-селкетә. Кызның ым кагып ризалашуын күргәч кенә, ул бераз тынычлана төште. Иелеп,

pixabay.com

колагына нидер пышылдады да кырт борылып китеп барды. Тегесе эскәмиягә килеп утырды, битараф карашын билгесезлеккә төбәп, тын калды.

– Нәрсәгә җилтерәтә ул сине? – дип, уеннан бүлде кызны бу тамашаны күреп торган әби. – Йөрмә син аның белән, бер дә әйбәт малай түгел ул. Карчыкка кызы да, аның егете дә таныш иде, күрәсең.

– Йөрмим, башка очрашмыйк, дигән идем, яный. – Кыз елап җибәрде.

– Елама, балам, елама, кайт та әти-әниеңә әйт. Ялгыз түгелсеңдер ич.

– Ялгыз шул менә, – диде кыз, кинәт елавыннан туктап. – Әти дә, әни дә юк минем. Укытучыларыма да әйтә алмыйм. Мине беркем якламый.

Күңелдән бер дә китми торган хатирәләр була. Мондыйлары әледән-әле искә төшеп, йөрәкне айкап куя. Нигә искә төшәме? Ә чөнки без көчле дип санаган, терәк ул, таяныч ул, дип мактаган ирләребез еш кына кая куярга белмәгән гайрәтләрен әнә шулай чәчә, явызлыгын әнә шулай хатынын кыйнап-җәберләп чыгара. Буйсындыра үзенчә, «бәйдә» тота… Ә иң кызганычы, хәтта хәтәре дип әйтер идем, ул залимнар якыннарына кылган җинаять өчен җәзага тартылмаячакларын белә. Чөнки бездә законнар шундый.

…Кайберәүләр гаиләдәге җәбер-золымны конфликт белән бутыйлар. Шуңа да аңа тыкшынырга кирәкми дип саныйлар. Конфликт аша ир белән хатын бергә яшәүнең тагы да отышлырак, яхшырак юлларын таба. Ә җәбер-золым ул – иң авырлардан саналган җинаять эше. Монысы инде хатын кыйнаудан тәм табучылар колагына…

Мәдинә АВЗАЛОВА

Авыл язмалары

Үзгә җәй

Җәйләрнең төрлесен күргән өлкәннәр дә шулай ди. Елдагыдан 15–20 көнгә алдан килгән өчен түгел. Күп җирдә корылык булган өчен дә, инде кыраулар бетәргә тиешле вакытта яшелчәләр өшерлек итеп кырау төшкәнгә, корткыч-бөҗәкләр чамасыз күп булганга... гына да түгел.

Аларның һәркайсы җәйне үзенчәлекле итәргә сәләтле, әмма быел бөтенесе бергә булды. Кайчан яз башланды, кайчан җәйгә күчтек, инде көзгә кереп барыш... Нигәдер күчеш чорларын да аңлап өлгерә торган булмады. Кыскасы, сюрпризларга бай җәй булды бу.

Календарьда әле җәй уртасы булса да, бакчалар акрынлап бушый башлады. Сарымсак, суганнар иртә өлгерде. «Көне тулды, өстәмә яңа тамыр җибәрә башлады», – дип, беребездән беребез күреп, аларны җыйнап алдык инде. Уңышы күп кешедә, сортына карап, елдагыча булды дип беләм. Бу җәй йогынты ясамаган сирәк культуралар шулар булды, ахры. «Кишер белән чөгендер дә бар бит әле», – диючеләр булыр. Тик безнең якларда алар белән язлыкта проблемалар булды: күп кешедә бигрәк тә кишер орлыклары тишелмичә аптыратты, яңадан утыртучылар да булды. Алар соң көзгә кадәр үсә, өлгерерләр әле, дисәк кенә инде.

«Кыраулардан исән калган ташкабак, баклажан, помидорлар да бик әйбәт үсте, уңышы мул», – ди күпләр. Кабакларның әле үсәргә көне күп. «Әллә ничә төрле сортларын утыртып караган идек, ташкабакның барысы да күкрәп үсте, ашап та, эшкәртеп тә бетерә торган түгел, маллар рәхәтләнә инде», – ди туганыбыз. Авылда шунысы бик рәхәт: уңган яшелчәләрнең берсе дә әрәм булмый, үзеңнән артканы – малларга менә дигән азык (алмаларны да бик яратып ашый алар).

«Башка елны бу вакытка инде кәбестәләрне берничә тапкыр агулый идек, быел ни хикмәттер, алар корткычларга бик бирешми әле», – ди кәбестә үстерүчеләр. Корткычлар, дигәннән, ул мәлгуньнәр елдан-ел арта гына бугай. Элек карлыганнарга иртә язда кайнар су сибә яки, өлгерми калсак, соңрак нәрсәдер (тәмәке порошогы иде дип истә калган) сибә идек. Башка әйберләргә ниндидер агу-химикатлар сипкәнне хәтерләмим. Хәзер интернеттагы бакчачылык белән шөгыльләнүчеләр тупланган берәр төркемгә язылсаң, аны укыганда күзләр маңгайга менә! Иртә яздан кара көзгә кадәр бөтен нәрсәгә әледән-әле нәрсәдер сибәсе дип киңәш бирәләр. Кыяр-помидорларга да су сибүдән башканы белми идек. Хәзер яшелчәләре дә нәрсәдер сипкәнне көтеп утыра. Помидорлар ярый әле, аларны фитофтороздан саклау чаралары күрсәң, суын сипсәң, иртә кызарсын, уңышы артсын, помидорлары эре булсын өчен дигәннәрен кулланмасаң да, үсәләр. Ә менә кыярлар, дөрестән дә, бик нәзбереккә әйләнеп бара. Әле яфраклары саргая, әле ниндидер таплар чыга, әле корыша... Теплицадагылары бигрәк тә күп игътибар сораса (шунсыз алардан күп уңыш алам димә), көннәр җылынды инде дип алданып, ачык туфракка иртәрәк утыртканнары да быел уңыш белән сөендерергә ашыкмады: кыярлары соң төште.

Быелгы җәйнең тагын бер «сәер»леге: бер үк культура бер бакчада әйбәт, икенчесендә берәү дә юк. Бу кадәресе бигрәк тә җиләк-җимешләрдә күренә: әйтик, алмагачлар быел күп кешедә сыңар чәчәк тә атмады, алмасы да булмады. Ә кемнәрдәдер бүген агачлары сыгылып утыра, башка еллардагы кебек, алма коела... Кемдәдер виктория бөтенләй булмады, кемдер уңышына сөенеп туя алмады. Теләсә нинди елны шаулап үсә торган безнең җиләкләр дә быел шактый ким булды. Юкса, алдагы елларда да әллә ниләр сипми идек. «Картинадагыдай ясап куйган җиләкләр кебек утыралар, нишләтәсез?» – дигән күршеләргә дә: «Кырдагы җиләкләргә беркем дә берни сипми, үсәләр әле, сез дә үсегез дип, су гына сибәбез», – ди идем. Быел булышмады. Карлыган, чия, кура җиләге белән дә шул ук хәл. Кемдәдер күп, кемдәдер юк... Булганда кадере юк, булмаса, кирәк икән, диеште башка елны коелганнары өстеннән таптап йөргән, мал-туарга ашатып, нишләтергә белми аптыраган кешеләр, алмалы бакчаларын сагынып.

– Быел бездә дә алмалар аз булды. Бер дә булмаган ише түгел үзе. Карлыган, кура җиләкләре бик күп булды, чияләрне әйтәсе дә юк. Бөтен туганнарны өмәгә чакырдым әле, килеп җыеп китегез дидем, – дип көлә Балтач районының Яңгул авылында яшәүче танышым Сәлимә Габделхакова. Сәлимә бакчачы түгел, әмма бакчаларында ел да бик күп төрле яшелчә, җиләк-җимешләр үстерүләрен (чәчәкләрне әйткән дә юк) беләм. Шуңа да: «Быел кавын-карбызларыгыз ни хәлдә?» – дип сорамый кала алмадым.

– Быел утыртмаган идек. Теплицада гына үстерә идек без аларны. Урынны шактый күп ала. Кыяр-помидор үстерсәк, күпкә файдалырак дип уйладык. Быел яз иртә килде, тышта да өлгергән булыр иде дип уйлаган идем, июнь уртасындагы кырауда калмаган булыр иде, белми дә калдык бит, дип сөендем инде. Сливага да салкын тиде, алар да юк быел. Виноградларга да зыяны булды. Булганында яраткач, булмаганында шөкер итәсең инде, – ди ул.

Барыбызга да шулай дияргә кала.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ИЯЛӘШКӘН ЕФӘК КОРТЫ...

Борчыган мәсьәлә

Быел агачлар шәрәләнде. Урманнарда да, паркларда да яфраксыз калган агачлар шактый. Сәбәбе – аларның яфракларын ефәк корты (шелкопряд) ашаган. Бу хакта без бер язган идек инде. Бөтен кешене хафага салган кортлар турында урманчылар белән сөйләштек. Белгечләр, агачлар өчен борчылмагыз, алар яңарачак, дип тынычландыра.

«Татар-информ»

Татарстан урманчылары ефәк корты һөҗүменнән соң ниләр эшләргә җыена? Киләсе елда да быелгы хәл кабатланмасмы? Инде күп җирләрдә, ефәк корты ашап киткәннән соң, агачлар яңадан яфрак ярган. Бу – тынычланырга сәбәпме? Урманчыларга бу юлы шул сорауларны бирдек.

Нурлат урманчылыгы җитәкчесе Рөстәм Галиев, агачлар яңадан яфрак ярды, дип шатландырды.

– Язын агачларның шәрә утыруы бер дә матур түгел иде инде. Ефәк кортын бу кадәр зыян салыр дип көтмәгән идек. 2021 елда беренче тапкыр килеп чыкты алар. Салкын кышка өметләндек. Кортлар салып калдырган йомыркалар салкында туңар дип уйладык. Тик булмады. Кышның артык салкын килмәве сәбәпле, ефәк корты рәхәтләнеп үрчеде. Өч ел рәттән бу кортлар яфракларын ашаса, агачларга зыян зур булачак. Алар корырга да мөмкин, – ди Рамил Галиев. – Без кулдан килгәнне эшләдек. Барлык таләпләргә туры китереп, урманнарны биологик препаратлар белән агуладык. Әмма бу эшләрне авылдан, елгадан, умарталардан 3 чакрым ераклыкта гына башкарып була. СанПиН таләбе шундый.

Урманчылар яшерми: агуларга ярамаган урыннарда кортларны бетереп тә булмый. Алар әлеге дә баягы салкын кышка өметләнә. Башкача бер чара юк. Әгәр инде кыш җылы килеп, ефәк корты салган йомыркалар туңып үлми икән, бу очракта агуны самолеттан сиптермәкчеләр. Болай эшләгәндә, ефәк кортыннан котылу мөмкин булачак.

– Самолеттан сибә торганы да биологик препарат аның. Без ул даруның кешегә дә, тирә-якка да зыяны булмавын ачыкладык. Бал кортларына да зыяны юк, диделәр. Димәк, тагын да бу кортлар күренсә, курыкмыйча сиптерергә булачак. Күктән сибүгә өмет зур – ул тиешле урыннарга барып җитәр дип уйлыйбыз, – ди Рөстәм Галиев.

Бөгелмә урманчылыгы җитәкчесе Гөлнара Мөхәммәтханова әйтүенчә, ефәк корты аларга да килеп җиткән.

– 2014 елда без моның белән очрашкан идек инде. 10 ел дигәндә, тагын агачларга зыян салдылар. Ул елны без бу бөҗәкләрдән агуны самолеттан сиптереп кенә котыла алдык. Кулдан сиптергәндә, препаратның барлык агачларга да эләгүе икеле, – ди урманчы. – Безгә ефәк корты күрше Башкортстаннан керде. Иң элек Азнакай урманнарына күчте, алардан – безгә. Оренбург ягындагы урманнар чиста. Аларда бу проблема юк.

Гөлнара Мөхәммәтханова: «Без агуласак, күршеләрнекеләр дә бетәчәк, алар дару сибә икән, бездә дә кимеячәк», – ди. Шунысы сөендерә: Бөгелмәдә зыян күргән агачлар яңадан яфрак ярган.

– Быел ефәк кортының ата күбәләкләре күп очып йөри. Ана күбәләкләр үз эшен эшләгән инде. Алар агачларга йомыркаларын салган. Бу кортларны салкын гына куркыта алачак, – ди ул да.

Урманчы бакчасы булган кешеләргә дә киңәш бирде.

– Ефәк кортлары агачның аскы өлешенә, җирдән 70 сантиметр биеклектә йомыркаларын сала. Алар ачык көрән төстә була, йонны хәтерләтә. Шуларны күрсәгез, алып ташлагыз, – ди ул. – Без, урманчылар, өметне өзмибез. Ефәк күбәләге 9–10 елга бер килеп чыга. Аның белән ничек көрәшүнең нәтиҗәле икәнен дә белдек. Әлеге вакытта зыян килгән урыннарны исәпләп чыгардык. Бөтенләй бу корткычлардан котылу өчен, препаратларны күктән сиптерү кирәк. Бары тик шулай эшләп кенә без ефәк кортыннан котыла алачакбыз.

Татарстанның урман хуҗалыгы министры урынбасары Илгизәр Зарипов әйтүенчә, Азнакай, Аксубай, Әлки, Биләр, Минзәлә, Нурлат һәм Чирмешән урманчылыклары урман фондында ефәк күбәләкләре 2022 елда табылган.

– Ел дәвамында урманнарда корткычларны тикшерүләр үткәрелә. Аларны бетерү өчен Урман хуҗалыгы федераль агентлыгына нигезләмәләр әзерләп җибәрдек. 2023 елның маенда Азнакай, Аксубай, Әлки, Биләр, Минзәлә, Нурлат һәм Чирмешән урманчылыклары территорияләренең бер өлешендә урман корткычларын бетерү буенча чаралар уздырылды, – ди ул.

Татарстанда 53 мең гектар мәйданда ефәк кортын бетерү буенча эшләр башкарылган. Агачларны биологик препарат ярдәмендә җир өсте ысулы белән эшкәрткәннәр. Ефәк күбәләгеннән зыян сала башласалар гына агулыйлар икән.

– Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: 2023–2024 елларда көчле салкыннар булса, мондый урман корткычларының йомыркалары туңачак һәм алардан кортлар чыкмаячак, – ди Илгизәр Зарипов. – Шуңа күрә урманнарны корткычларга каршы эшкәрткәнче, яз көне аларның санын контрольдә тотабыз. Әгәр тикшерү эшкәртү кирәклеген күрсәтсә, агулыйбыз. Моннан тыш, көзге чорда Татарстанда ефәк күбәләге йомыркаларын нефть белән эшкәртү үткәреләчәк. Бу чара әлеге корткычның популяциясен киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Белеп тор!

✓ Ефәк корты күбәләге 10 көн генә яши, үзе берни дә ашамый.
✓ Сезонга бер тапкыр 300–1200ләп йомырка сала. Язын шул йомыркалардан чыккан гусеницалар, бик тиз үсеп җитеп, яфрак согы белән тукланалар.
✓ Ефәк корты аеруча имән, тупыл һәм бакчадагы җимеш агачларын ярата.
✓ Корткычларны куркыту өчен, агачка сумала, машина мае һәм махсус препаратлар сеңдерелгән «билбау»лар бәйләргә кирәк. Болай эшләгәндә кәүсәнең түбәнге өлешендә яки коры яфрак астында кышлаган гусеницалар өскә үрмәли алмый.
✓ Ефәк кортын кошлар да яратмый.

ЙӨЗЬЯШӘРНЕҢ – ҮЗ КАГЫЙДӘСЕ

Соклану

Аңа мунчаның кайнары, ризыкның тәмлесе кирәк. Киемнең дә бары үтүкләгәнен генә кия ул. Юк, картлык көйсезлеге түгел бу. Баулы районының Татар Томбарлысы авылында яшәүче 9 июльдә 100 яшен тутырган Фәхриҗамал әби Шарапованың яшәү рәвеше шундый. Әле һәр иртәсе күнегү ясаудан башлана. Гаҗәп әби бит, килешәсездер?

Бу әбине кем шулай көйләп тора соң, дисезме? Аны кадер-хөрмәттә яшәтүче Сәрия апа Гыйльфанованың үзенә дә киләсе елда җитмеш тула. Фәхриҗамал әбинең кызы да, туганы да түгел ул. Сәрия мәрхүм каенанасы Гафифәнең кияүгә чыкмаган сеңлесен әнә шулай тәрбияли. Каенатасын, каенанасын да олылап соңгы юлга озаткан. 45 ел бергә яши-яши Фәхриҗамал карчык исә аның иң якын кешесенә әйләнгән. Бервакытта да арада тавыш чыкмаган. Гомер буе әби кушканча гына эшләгән. Кайчак берәр сүз әйтеп куйса, син икенчеләнден әле, Сәрия, дип куя икән. Шуңа күрә ул аның кагыйдәләрен беркайчан да бозмаска тырыша. Әбинең өс-башы, мунча киемнәре, сөлгеләре һәрвакыт үтүкләнгән. Юкса ул аны кимәячәк. Аерым кашык, чынаяк, аерым бал, кайнатма, май савыты... Әмма бу аерым ашау дигән сүз түгел.

– Кайберәүләр: «Нигә табынга икешәр савыт бал, кайнатма куясың?» – дип шакката. Үзе шулай тели икән, ашасын, дим. Ул миңа әни кебек якын. Картлар йортына бир, диючеләр дә бар. Мин аннан соң нинди намус белән яшим, ди? Аны илтеп куйган очракта да ул анда яши алмаячак. Үзенчә яшәргә күнеккән бит. Анда бөтенесе – бергә. Шуның өчен беркая да җибәрмәячәкмен. Үзем исән булганда карыйм әле. Кызларым Светлана, Рәмилә дә бик әйбәт, ташламаслар, – ди Сәрия апа.

Моңа кадәр Сабан туена да йөрткән әле ул аны. Тик быел, колагым ишетми, дип бармаган. Сәбәбе дә бар: Коръән ашына чакырулы булганнар.

Сәрия апа әбине үзенчә матур итеп киендерергә тырыша. Тик әбекәйнең генә моңа исе китми икән. Аның каравы сәламәтлегенә битараф түгел. Һәр иртәдә ишегалдына чыгып, күнегүләр ясый. Кичләрен исә аяк-кулларын тагын бер мәртәбә язып керә. Әби сәламәтлегеннән зарланмый. Әмма, кай җиреңавырта, дип сораганда, бар әгъзам да, дип әйтә икән.

Аның кызу мунча яратуы – үзе бер хикмәт. Җитмәсә, беренче булып бара икән әле. Кызу булмаса, кереп тә тормый.

– Мунчаны 1–1,5 сәгать керә. Басып юына, бервакытта да утырмый. Мин чәчләрен юып, аркасын ышкыгач, өйгә кайтып китәм. Мине саклап утырма, ди. Мунчадан битләре кып-кызыл булып кайтып керә. Аңа шулай рәхәт, – ди Сәрия апа Гыйльфанова.

Шулай да озын гомер сере нидә икән соң? Сәрия апа, әйбәт ашаудадыр, дип саный. Ни өчен дигәндә, гомер буе җиләк-җимеш ашаган. Лимонлы чәй эчкән. Балдан, майдан, җимеш, чикләвектән өзелмәгән. Ит яраткан. Тик тешләре булмагач, хәзер ашый алмый.

Әле юбилее белән котларга район, үзе укыткан мәктәп (Фәхриҗамал Шарапова – Татарстанның атказанган укытучысы. Ул Баулы шәһәрендәге 3 нче мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыткан. – **С.М.**) җитәкчеләре дә килгән икән. Кирәкми мондый бәйрәмнәр, үзеңә мәшәкать ясап, табын әзерләп йөрмә, дигән булган йөзьяшәр.

– Киләбез дип торганда, кешегә ничек килмә, дисең? Юклык заманы түгел, бөтен нәрсә дә бар бит. Бер гасыр кичүеңне ничек бәйрәм итмисең?! – дип аңлаттым, – ди Сәрия апа.

Менә бит нинди игелекле, башкаларга үз кадерен белеп яшәргә ирек биргән, олыны олы итә белгән кешеләр бар дөньяда! Фәхриҗамал әбигә артык эш тә кушмаган. Чәй куеп торганга да риза булган. Ярты гасырга якын шулай тәрбияләә әле син?! Сәрия апа «Газпром» оешмасында слесарь булып хезмәт куйган.

Игелек җирдә ятмый, ул кешегә барыбер әйләнеп кайта, диләр. Сәрия апа да моның шулай икәнлегенә инанган. Йөрәк өянәгеннән инде исән калмам, дигәндә аякка басуын да кылган игелекләрнең әҗере дип саный ул.

– Каенанам 62 яшендә үлде. Бик дус яшәдек. Дөресен әйтәм, баштарак, син иркә, дип бик кабул итеп бетермәгән иде. Әтисез үскәч, эш рәтен белми дип уйлаган. Чирләп урын өстендә ятканда, эштән китеп тәрбияләдем. Бергәләп хастаханәләрдә ятарга туры килде. «Бу кадәр яхшы булырсың дип белмәгән идем», – дип әйтә иде. Риза-бәхил булып китте. Каенатам Фатыйх та шулай. Ирем Миясәр 57 яшендә йөрәк чиреннән китеп барды. 31 ел гына яшәп калдык. Кадеремне белде, бармак белән дә чиртмәде. Бар эшне бергәләп башкардык. Ике кыз үстердек. Бүген дәрәҗәле урыннарда эшлиләр. Кешеләргә яхшылык кылып яшәгез! – ди Сәрия апа, әйбәт булырга чакырып.

Сәрия МИФТАХОВА

Сан

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, хәзерге вакытта Татарстанда **100** яшьлек һәм аннан өлкәнрәк **185** кеше гомер кичерә. Шуларның **165**е– хатын-кыз, **20**се – ирләр.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5091 данә
Гомуми тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде — Заказ 302

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+